| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«НИЖНЕЧЕРШИЛИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>«ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>«ТҮБӘН ЧЫРШЫЛЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |

02.09.2026 № 21

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2022 елның 18 августындагы 15 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге депутаты статусы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законга туры китереп, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2022 елның 18 августындагы 15 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге депутаты статусы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Депутат вәкаләтләре сайланган көннән башлана һәм яңа чакырылыш Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының хокуклы составтагы беренче утырышын уздырган көннән туктатыла..».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Түбән Чыршылы авылы, Үзәк урамы, 105 йорт адресы буенча административ бинада, Мельничная урамы, 23 йорт буенча ФАП бинасында, Югары Чыршылы авылы, Горная урамы, 27 йорт авыл мәдәният йортында, Мордовская Ивановка авылы, Совет урамы урамы, 13 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стенында, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) халыкка җиткерергә.

« Түбән Чыршылы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе
Н.Я. Хәйруллина